СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 г.Зеленодольск № 67

2022 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән, Зеленодольск шәһәре Советының 2016 елның 27 июнендәге 64 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тәкъдим иткән 2022 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) проектын карап, Зеленодольск Советы **карар итте**:

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) кушымтада бирелгән тәртиптә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына 2022 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) «Интернет» челтәрендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында

(http://zelenodolsk.tatarstan.ru), торглар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (http://www.torgi.gov.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Совет рәисе** **М. П. Афанасьев**

Зеленодольск шәһәре Советының
2021 елның 17 декабрендәге
№67- ТРЗ карарына кушымта

**2022 елга**
**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. 2022 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон , Зеленодольск шәһәре Советының 2016 елның 27 июнендәге 64 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә эшләнгән.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең мөлкәтен хосусыйлаштыру шәһәр милке структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, шәһәр бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлдерелгән.

3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы Федераль законда каралган ысуллар белән гамәлгә ашырыла.

4. 2022 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) гамәлдә булганда, хосусыйлаштырыла торган мөлкәт исемлегендә Зеленодольск шәһәре Советы карарлары нигезендә үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

II. 2022 елда хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

Хосусыйлаштыру планлаштырыла торган башка мөлкәт исемлеге

| № т/б | Атамасы | Мөлкәтнең урнашу урыны | Хосусыйлаштыруның фаразланган срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | Кадастр номеры16:49:010206:89 булган 264 кв.м. мәйданлы торак булмаган бина, кадастр | Татарстан Республикасы, Зеленодольск | 2022 елның I-IV кварталы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | номеры16:49:010206:19  булган 589 кв.м мәйданлы җир кишәрлеге белән. | шәһәре, Кызыл тыкрык ур., 6 | |
| 2 | Кадастр номеры16:49:010206:927 булган 252 кв.м. мәйданлы торак булмаган бина, кадастр номеры16:49:010206:23  булган 589 кв.м мәйданлы җир кишәрлеге белән. | Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Кызыл тыкрык ур., 14 | 2022 елның I-IV кварталы |